# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Янгын куркынычсызлыгы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2008 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

"Янгын куркынычсызлыгы турында" 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11-12; 1994, № 1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

бишенче абзацка ", шулай ук янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү" сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацта "янгыннан саклау" сүзләрен "янгынга каршы хезмәтенен" сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Авыл торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү буенча җирлекләр һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

янгыннан ирекле саклануны оештыру өчен, шулай ук янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүдә гражданнарның башка рәвешләрдә катнашулары өчен шартлар тудыру;

янгын сүндерү максатларында авыл торак пунктларында һәм алар тирәсендәге территорияләрдә урнашкан су белән тышкы якта тәэмин итү чыганакларыннан елның теләсә кайсы вакытында су алу өчен шартлар тудыру;

янгыннар сүндерүнең беренчел чаралары һәм янгынга каршы инвентарь белән гомуми файдаланудагы территорияләрне тәэмин итү;

халыкка һәм Янгынга каршы дәүләт хезмәте бүлекчәләренә янгын турында хәбәр итүне оештыру һәм хәбәр итү чараларын күрү;

Янгынга каршы дәүләт хезмәте бүлекчәләре килеп җиткәнчегә кадәр янгынны локальләштерү һәм халыкны, мөлкәтне коткару чараларын күрү;

җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләре үсеше планнарына, схемаларына һәм программаларына янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын кертү;

янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирүдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына ярдәм күрсәтү, шул исәптән халык җыелышларын оештыру һәм үткәрү юлы белән дә;

янгын куркынычы арткан очракта, янгынга каршы махсус режим билгеләү.

Шәһәр торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү буенча җирлекләр һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

янгыннан ирекле саклануны оештыру өчен, шулай ук янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүдә гражданнарның башка рәвешләрдә катнашулары өчен шартлар тудыру;

җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләре үсеше планнарына, схемаларына һәм программаларына янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын кертү;

янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирүдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына ярдәм күрсәтү, шул исәптән халык җыелышларын оештыру һәм үткәрү юлы белән дә;

янгын куркынычы арткан очракта, янгынга каршы махсус режим билгеләү.

Җирлекләрнен, шәһәр округларының торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгынын беренчел чараларын оештыру-хокукый, финанс, матди-техник тәэмин итү мәсьәләләре җирле үзидарә органнарының норматив актлары белән билгеләнә.";

3) 19 статьянын әченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару өчен янгыннан саклану бүлекчәләре, янгыннан саклану гарнизоннары көчләрен һәм чараларын җәлеп итү тәртибе янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан,Кремль
2008 елның 23 июне

№ 26-ТРЗ